# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФӘННИ-ЭЗЛӘНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ.

# МАСТЕР КЛАСС

***«Укучыларның проект эше белән идарә итү»***

***проект өстендә эшләү*** –

ул әле булмаган әйберләр булдыру, ягъни булдыру ысулларын күрсәтү

**Максат:** *Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә фәнни эзләнү эшчәнлеге методларын куллану эше тәҗрибәсе белән уртаклашу*

**Бурычлар**

1. *Проект эзләнү эшенең төрләре белән таныштыру.*
2. *Проект эшчәнлегенең эш этапларына күзәтү ясау.*
3. *Проект эшен булдыру практик күнекмәләр формалаштыру.*

**ФЭ методы**

↓

Укучыларның дөньяны танып белү мөмкинлекләрен,акыл эшчәнлеге мөстәкыйльлеген үстерүнең төп нигезе

# НӘРСӘ СОҢ УЛ ФӘННИ-ЭЗЛӘНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ.???

1. Укучыларның югары теоретик белеме
2. Белемнәрне гомумиләштерү өчен эш алымнарын үзләштерү
3. Фикер йөртүгә фәннилек кертү
4. Фәнни хезмәтне яклау ысуллары

# ФӘННИ ЭЗЛӘНҮ ЭШЛӘРЕ

**ПРОЕКТ**

Проектның асылы – белем алу шартларында туган проблеманы чишү ысулларын ачыклау

**ЭЗЛӘНҮ**

Эзләнүнең асылы – алган белемгә таянып билгеле бер объектка юнәлтелгән теория һәм практиканы гомумиләштереп фараз (гипотеза) яклау

Үзенчәлеге

- Проект эшчәнлегендә нәтиҗәдә һәрвакыт продукт була
- Проект кыска вакытлы булырга мөмкин
- Проект
  - Проблема
  - Гамәлгә ашыру нияте
  - Реализация
  - Рефлексия
  - Презентация
- Продукт: реферат, спектакль,доклад, газета, фильм, ярдәмлекләр,альбомнар


- Эзләнү эшчәнлегенең төп продукты – ул яңа белемнәр
- Ешрак эзләнү озак вакытны таләп итә
- Эзләнү
  - Кызыксындырган сорау
  - Гипотеза чыгару
  - Чыганаклардан эзләнү
  - Теоретик белемнәрне гомумиләштереп
  - Тупланган һәм эшкәртелгән мәгълүматларга таянган чыгыш  ясау

# НӘТИҖӘ

## ГББК формалаштыру

- мөстәкыйль фикер йөртү
- төрле ситуацияләрдә белемнәрен куллана белү
- көндәлек проблемаларга иҗади һәм фәнни карау
- максат кую һәм эш тәртибен билгеләү
- фәнни мәгълүматларга таянып үз фикерләрен дәлилләү
- өстәмә информацион чыганаклар эзләү
- табылган мәгълүматларны куллану
- билгеле бер проблеманы яктырткан информацияне гомумиләштерү
- мөстәкыйль эшчәнлек алып бару

# Әзерлек эше


Дәрес
проблемалы ситуацияләр
Мөстәкыйль фәнни фикер
Диалог

# ПРОЕКТ ЭШ ҮРНӘКЛӘРЕ

*башлангыч сыйныф:*

- Минем гаиләм ( стенд)
- Үсемлекләр (рәсемле таблица)
- Шәһәрләр (карта)
- Килеш кушымчалары ( ярдәмлек)
- Татар костюмы (презентация)

***5-8 нче сыйныф:***

- Татар һәм рус бәйрәмнәре ( таблица, мәкалә)
- Истәлекле урыннар ( доклад)
- Безнең шәһәр ( презентация)
- Татар теле үзенчәлекләре ( чагыштырма схемалар)
- Синоним сүзләр (сүзлекчә)

# ПРОЕКТ ЭШ ҮРНӘКЛӘРЕ

***9 – 11 нче сыйныф:***

- Чаллы язучылары ( доклад –презентация)
- Татарлар чыгышы ( альбом, мәкалә)
- Бәйлек сүзләр ( таблица)
- Сүзләр тарихы ( сүзлек)
- Кушма җөмлә ( ярдәмлек)
- Татарларның язу тарихы (күрсәтмә-доклад)
- Алынма сүзләр ( доклад –презентация)

# «ПРОЕКТ» - ФАРСЫ ТЕЛЕННӘН *АЛГА АТЛАУЧЫ, АЛДАН БАРУЧЫ* ДИГӘННЕ АҢЛАТА

***проект методын*** куллану – ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, «белү һәм белмәү» зонасында мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, дулкынлардырган проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу.

# ПРОЕКТНЫ БУЛДЫРУ ӨЧЕН ЭШ ЭТАПЛАРЫ.

## Эзләнү этабы

| укучы | укытучы |
|---|---|
| -кызыксындырган сорауны билгели, үз фикерен дәлилли;<br>-информацион чыганаклар туплый | -күзаллауны киңәйтүче темалар тәкъдим итә;<br>-проблемалы ситуацияләр тудыра;<br>-укучыларның сорауларына җавап табу өчен тематик цикләрне билгели |

# АНАЛИТИК ЭТАП

| укучы | укытучы |
| --- | --- |
| - информацияне системалаштыра;<br>- булачак «туачак» продуктны кузаллап тасвирлый;<br>- эш планын төзи | - күзәтә, алга этәрүче сорау һәм ситуацияләр булдыра;<br>- укучының хронологик тәртиптә эш итүе белән идарә итү;<br>- консультацияләр оештыра |

# ПРАКТИК ЭТАП

| укучы | укытучы |
| --- | --- |
| -мөстәкыйль рәвештә план буенча эшли;<br>- эшнең барышы белән уртаклаша | - мөстәкыйль эшләү мөмкинлекләрен булдыра;<br>- эш барышына карата анализ ясый;<br>- «проект дәфтәре» булдыру эшен оештыра |

# ПРЕЗЕНТАЦИОН ЭТАП

| **укучы** | **укытучы** |
| --- | --- |
| - проектны презентациялəү формасын сайлый;<br>- эксперт ролен үти (башка укучыларга карата) | - бəхəс тудыручы сораулар əзерли;<br>- проектны кабул итəргə əзер булган аудитория əзерли |

# КОНТРОЛЬ ЭТАП

| укучы | укытучы |
|---|---|
| - бәяләү нормаларына туры китереп, проектка үзбәя бирә | «проект дәфтәре» булдыру эшен йомгаклый;<br>- алдагы үсеш юлларын ачыклый |